# КАРАР

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге составына керүче Түбән Сауруш торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

2019 елның 27 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Саурыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендәге 96 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2019 елның 27 ноябрендә мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез 2019 елда Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге Түбән Сауруш торак пункты (авылы) яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәм киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

**1.Авыл җирлеге чикләрендә, шул исәптән җирлек чикләрендә җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

1). Түбән Сауруш торак пунктында (авылында) вак таш җәелгән юлларны ремонтлау.

2).Түбән Сауруш авылы урамнарын карап тоту.

3). Түбән Сауруш авылында буаны ремонтлау.

**2.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп).**

1). Түбән Сауруш авылында урамнарны яктырту өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

**«ӘЙЕ», «ЮК».**

**Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:**

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 156 кеше кертелгән; тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 87 кеше

**Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:**

- «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы **87** кеше тавыш бирде;
- «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның **0** кеше тавыш бирде.

**Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге составына керүче Түбән Сауруш торак пунктында (авыл) гражданнар җыенын - **үткәрелгән дип танырга**, халык җыенының нәтиҗәләрен **чын дип танырга**.

2. «Сез 2019 елда Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге Түбән Сауруш торак пункты (авылы) яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәм киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

**1.Авыл җирлеге чикләрендә, шул исәптән җирлек чикләрендә җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

1). Түбән Сауруш торак пунктында (авылында) вак таш җәелгән юлларны ремонтлау.

2).Түбән Сауруш авылы урамнарын карап тоту.

3). Түбән Сауруш авылында буаны ремонтлау.

**2.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп).**

1). Түбән Сауруш авылында урамнарны яктырту өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу,- мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Саурыш авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларын түбәндәге адреслар буенча игълан итәргә: ТР, Аксубай районы, Иске Саурыш авылы, Комсомольская урамы, 20 йорт; Түбән Сауруш авылы, Центральная урамы, 22 йорт; Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Саурыш авыл җирлеге башлыгы А. Г. Кузьмин